КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 24 июнь г.Казань № 510

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2018 ел, 28 февраль, 128 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2018 ел, 28 февраль, 128 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 31 октябрь, 972 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның беренче абзацында «күпфатирлы йортларда бүлмәләр милекчеләренең гомуми мөлкәте» сүзләреннән соң «күпфатирлы йортта бүлмәләрне үзгәртеп планлаштыруны һәм (яки) үзгәртеп коруны гамәлгә ашыру тәртибе,» сүзләрен өстәргә;

23 пунктның 2 пунктчасына «бу йортта гомуми мөлкәт» сүзләреннән соң «күпфатирлы йортта бүлмәләрне үзгәртеп планлаштыруны һәм (яки) үзгәртеп коруны гамәлгә ашыру тәртибе таләпләрен бозу фактлары турында,» сүзләрен өстәргә;

29 пунктның 4 пунктчасында «милекчеләрнең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре» сүзләреннән соң «күпфатирлы йорттагы бүлмәләрнең» сүзләренә өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин